**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

7 апрель 2016 ел № 13/3

Тукай муниципаль районының «Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе хакында

«Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясы, «Россия Федерациясенең аерым дәүләт вазыйфаларын, федераль дәүләт хезмәте вазыйфаларын биләүче затлар һәм вазыйфаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин булган шәхси кызыксыну барлыкка килү һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 22 декабрендәге 650 номерлы Россия Федерациясе Президентының Указының 8 пункты нигезендәм униципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районының « Кече Шилнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затларның вазыйфаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр конфликтына китерә торган яисә китерергә мөмкин шәхси кызыксынуы барлыкка килү турында хәбәр итү тәртибе турында нигезләмәне расларag (кушымта нигезендә).
2. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмат стендларында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында халыкка игълан итәргә.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккач үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек башлыгы,
Совет рәисе Г.Н. Харитонов